ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИДЕЛ БУЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.09.2020 №1-5

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Идел буе авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турында нигезләмәнераслау хакында» 2009 елның 09 сентябрендәге 55-2 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Идел буе авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Идел буе авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Идел буе авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Идел буе авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турында нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 09 сентябрендәге 55-2 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Идел буе авыл җирлеге советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Идел буе авыл җирлегендә гражданнарны сораштыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.11 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында «җирлек халкы өчен» сүзләрен өстәргә.

1.2. 8.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гражданнардан сорашып белешү үткәрү өчен җирлекнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайты файдаланылырга мөмкин.».

2. Әлеге карарны Идел буе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/www.spassriy.tatarstan.ru) һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Идел буе авыл җирлеге башлыгы: С.Г.Спирин

Совет Приволжского сельского поселения